КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 апрель г.Казань № 250

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 октябрь, 909 нчы; 2013 ел, 25 март, 200 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 990 нчы; 2014 ел, 25 ноябрь, 912 нче; 2015 ел, 16 июль, 522 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 985 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1084 нче; 2017 ел, 13 апрель, 224 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 962 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Фазлыева Ләйлә Ринат кызын, аның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итеп, Комиссия рәисе дип расларга:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары»;

Комиссия составыннан Р.И.Замановны, Р.Р.Зариповны, Л.О.Сулиманы, В.Г.Шәйхразиевны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Выборнов Андрей Андреевичны - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлеге башлыгы урынбасарын;

Гыйзетдинов Илфак Сөләйман улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Казан линия идарәсенең транспортта полиция (җәмәгать тәртибен саклау буенча) башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Хәдиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасарын, Комиссия рәисе урынбасарын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин